КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 август г.Казань № 846

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен

финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүчеләрнең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре 300 мең сумнан артмаска тиеш;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эш бирүчеләр экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Субсидия алу максатында сайлауда катнашу өчен, эш бирүче үзенең урнашкан (эш бирүче филиалы урнашкан) урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча субсидия бирүгә заявка (алга таба - заявка) бирә.

Заявкага эш бирүче түбәндәгеләрне терки:

әлеге Тәртипнең 2.8 һәм 2.9 пунктлары нигезендә тиешле чыгымнар күләмен нигезләп субсидия күләмен исәпләү;

гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы документларның  эш бирүче имзасын куйган һәм мөһер белән (булганда) таныкланган күчермәләре;

эш бирүчене дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсен йә эш бирүченең имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган Юридик затларның (индивидуаль эшкуарның) бердәм дәүләт реестрын теркәү кәгазе күчермәсен;

салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, конкурс уздыру планлаштырылган айның 1 числосына бирелгән процентлар, салым түләүче тарафыннан Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы үтәлеше турында белешмә формасын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым органының белешмәләре;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы каршында үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында эш бирүче җитәкчесе һәм баш хисапчысы (булганда) кул куйган, мөһер сугылган белешмә кәгазе;

эш бирүченең бу Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

эш бирүче – юридик затның үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы юридик затка, башка юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, эш бирүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә эш бирүче – индивидуаль эшмәкәрнең үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавын раслый торган, җитәкче (индивидуаль эшмәкәр) тарафыннан имза куелган, мөһер белән (мөһере булганда) расланган белешмә кәгазе;

коллегиаль башкарма орган җитәкчесенә, әгъзаларына, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затка яки баш бухгалтерга (баш бухгалтеры булганда), индивидуаль эшмәкәрләргә Федераль салым хезмәтенең «Дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү тәртибен, дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм соратып алына торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе формаларын раслау хакында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) соратыла торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе;

эш бирүче - юридик зат чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмавын раслаучы җитәкче тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән (булганда) таныкланган белешмәләр;

эш бирүченең яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу сәбәпле халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чикләү чаралары булмау турында белешмә;

эш бирүченең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый икәнен раслый торган белешмә.

Эш бирүче тарафыннан бу пунктның бишенче – алтынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештырганда эш бирүче заявкага өстәмә рәвештә теркәп куя:

вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештырганда матди-техник тәэмин итүгә чыгымнар сметасы проекты;

планлаштырылган вакытлыча эш белән тәэмин итү төрләрен һәм хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырылачак һөнәрне характерлаучы ирекле рәвештәге мәгълүмати белешмә;

эш бирүченең заявкада күрсәтелгән вакытка ирекле рәвештә 2022 ел дәвамында вакытлыча эш белән тәэмин итү йөкләмәсе турында гарантияле хаты.

Иҗтимагый эшләрне оештырганда, ул вакытлы яисә сезонлы эшләрне башкаруга ихтыяҗ булуын раслау өчен аварияләрнең, стихияле бәла-казаларның, һәлакәтләрнең һәм башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен тиз арада бетерү зарурлыгына бәйле булмаган һәм хезмәткәрләрне махсус әзерләүне таләп итмәгән, шулай ук аларның иң кыска срокларда квалификацияле һәм җаваплы гамәлләрен раслау өчен, заявкага өстәмә рәвештә теркәп куя:

ирекле рәвештә эшләүче хезмәткәрләргә ихтыяҗны, җәмәгать эшләре төрләрен характерлый торган мәгълүмати белешмә, вакытлыча яисә сезонлы характерга ия буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булдыру яисә аларны булдыру мөмкинлеге;

эш бирүченең ирекле рәвештә үзенә юлланган халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан 2022 ел дәвамында гаризада күрсәтелгән срокка җәмәгать эшләренә җибәрелә торган халыкны эш белән тәэмин итү йөкләмәсе турында гарантияле хаты.

Эш бирүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә эш бирүче турында, эш бирүче тарафыннан бирелгән заявка, сайлауны үткәрүгә бәйле эш бирүченең башка мәгълүматы турында мәгълүматны бастырып чыгару (урнаштыру) һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан эш бирүче тарафыннан субсидия бирү шартлары һәм тәртибен үтәүне, шулай ук аның электрон почтасы адресы заявкада күрсәтелә.

Эш бирүче тапшырыла торган документларның (белешмәләрнең) дөреслеге өчен җаваплы.

Аңа кушымта итеп бирелгән документлар белән заявка халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә ул кергән көнне теркәлә һәм аны теркәү чираты тәртибендә карала.

Заявка халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә почта элемтәсе оешмасы аша кергәндә, ул субсидия алу өчен заявкаларны теркәү журналында заявканың халыкны эш белән тәэмин итү  үзәгенә керү датасын һәм вакытын һәм заявкага тәртип буенча бирелгән теркәү номерын күрсәтеп теркәлә.

Сайлап алуны үткәрү чорында сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә  заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан эш бирүчеләргә  халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тиешле сорату кергән датадан биш эш көне эчендә электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.

Гаризалар кабул итү срогы тәмамланганчы эш бирүче  ирекле формада язма гариза буенча заявканы, шул исәптән заявкага үзгәрешләр кертү һәм яңа заявка бирү максатында, чакыртып алырга хокуклы.

Әгәр заявкага үзгәреш кертү эш бирүче тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылса яки эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан заявканы кире алу

турындагы хәбәрнамә заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр алынган булса, заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турында хәбәрнамә гамәлдә була.»;

2.6 пунктта:

алтынчы абзацта «максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

эш бирүченең, эш бирүче белән белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә субсидия акчасын алучы затларның үзләренә карата Министрлык, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант операторының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм Министрлык эш бирүчеләрнең субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, үтәвен тикшерә.

Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.5 пунктта «максатларын,» сүзен төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенең 2.1 пунктындагы өченче абзацының һәм 2.3 пунктындагы җиденче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин